ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2025 с. Старое Дрожжаное №529

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 30 апрелендәге 137/1 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктында 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфасы | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль бюджет яисә казна учреждениесе булган үзәкләштерелгән бухгалтерия |
| Башкарма комитет | 40 700 |

| | |
|---|---|
| Җитәкче урынбасары | 38 100 |
| Бүлек начальнигы | 33 600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер, икътисадчы | 30 600 |
| Хисапчы | 29 000»; |

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлар турындагы нигезләмәнең 3 пунктындагы таблицаны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| «Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш хисапчы | 31 000 | 32 700 |
| Хисапчы | | 29 700». |

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче Р.И. Мөхәммәтҗанов